ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2022 елның «23» августыннан № 236

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетыннан шәһәр һәм шәһәр яны юлларында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыручы юридик затларның һәм (яисә) индивидуаль эшкуарларның шәһәр һәм шәһәр яны юлларында муниципаль маршрутлар буенча даими рәвештә автомобиль транспортында пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыручы юридик затларның һәм (яисә) индивидуаль эшкуарларның алынмаган керемнәрен каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2022 елның 04 апрелендәге 111 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә даими пассажирлар йөртүне җайга салу һәм алар белән идарә итү системасын оештыру һәм камилләштерү, җәмәгать транспортында QR-кодлар кертүгә бәйле рәвештә, пассажирлар ташуны гамәлгә ашыручыларга алынмаган керемнәрен кайтару максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы, «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар һәм багажны даими йөртүне оештыру һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль законының 14 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетыннан шәһәр һәм шәһәр яны юлларында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә

ашыручы юридик затларның һәм (яисә) индивидуаль эшкуарларның шәһәр һәм шәһәр яны юлларында муниципаль маршрутлар буенча даими рәвештә автомобиль транспортында пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыручы юридик затларның һәм (яисә) индивидуаль эшкуарларның алынмаган керемнәрен каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2022 елның 04 апрелендәге 111 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

21 пунктның 8 абзацында «максатларын» сүзен «нәтиҗәләрен» сүзенә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына (икътисад буенча) йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов